ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.02.2016 Казан ш. № 18

Татарстан Республикасының
Туристлык буенча дәүләт комитетында
Татарстан Республикасы дәүләт
гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан
вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә
мәнфәгатьләр каршылыгына китерә
торган яки китерергә мөмкин булган
шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү
турында хәбәр итү тәртибен раслау
хакында

2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” № 273-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге “Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифаларын, федераль дәүләт вазифаларын биләүче затлар һәм бүтән затлар тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында” № 650 Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен расларга.
2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгын үз өстемә алам.

Рәис С.Е.Иванов

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 2016 елның
12 февралендәге
№ 18 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында
Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында
хәбәр итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында аларга карата эшкә алучының вәкиле булып Дәүләт комитеты рәисе торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – Дәүләт комитеты, гражданлык хезмәткәрләре) тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен регламентлый.

2. Хәбәр гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан шушы Тәртипкә карата Кушымтада китерелгән вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында белдерүнамә (алга таба – белдерүнамә) рәвешендә язмача төзелә һәм Дәүләт комитеты рәисенә җибәрелә.

3. Дәүләт комитеты рәисе өч эш көне дәвамында белдерүнамәне беренчел карап тикшерү өчен Дәүләт комитетында коррупцияне һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) җибәрә.

4. Белдерүнамәне беренчел карап тикшерү барышында җаваплы зат белдерүнамәне җибәргән гражданлык хезмәткәреннән анда бәян ителгән шартлар буенча аңлатмалар алырга, билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына, башка җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга гарызнамәләр җибәрүнең инициаторы булырга хокуклы.

5. Белдерүнамәне беренчел карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы зат нигезле бәяләмә әзерли.

Беренчел карап тикшерү барышында алынган белдерүнамә, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат белдерүнамәне алган көннән башлап җиде эш көне дәвамында аның тарафыннан Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе (алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырыла.

6. Шушы Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән гарызнамәләрне җибәргән очракта, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан Комиссия рәисенә белдерүнамәне алган көннән соң 45 көн дәвамында тапшырыла. Аталган вакыт Комиссия рәисе тарафыннан 30 көннән артмаган чорга озынайтылырга мөмкин.

7. Белдерүнамә, бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының “Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмә раслау турында” 09.09.2015 № 111 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмә нигезендә карап тикшерелә.

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибенә карата кушымта

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисенә

______________________________________
(Ф.И.А)

кемнән
______________________________________
(вазифаның аталышы)

______________________________________
______________________________________
(Ф.И.А., телефон номеры)

## Вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында белдерүнамә

Вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә миндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган (кирәклесе астына сызарга) шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәм.

Шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү өчен нигез булган шартлар:
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлык аларның үтәлешенә йогынты ясый яки ясарга мөмкин булган вазифаи вәкаләтләр:_____________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын бетерү яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: _____________________________________________________
____________________________________________________________________________

Шушы белдерүнамәне карап тикшергәндә Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим / ниятләмим (кирәклесе астына сызарга).

«____» _____________ 20___ ел. ______________________ ______________________
(белдерүнамә җибәргән затның имзасы) (имзаның аңлатмасы)